ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«10» июнь 2022 ел № 451

**«Арча муниципаль районы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 10 декабрендәге 1831 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 11 апрелендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Арча муниципаль районы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 10 декабрендәге 1831 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.4. Юл сервисы объектлары автомобиль кую урыннары һәм тукталыш урыннары, шулай ук аларга автомобиль юлыннан керү мөмкинлеген тәэмин итә торган подъездлар, съездлар һәм кушылмалар белән җиһазландырылырга тиеш. Шул ук вакытта, кагыйдә буларак, әлеге максатлар өчен бүлеп бирелгән җирләр чикләрендә бу объектларны комплекслы рәвештә урнаштырып, автомобиль юлыннан керү мөмкинлеген тәэмин итә торган подъездлар, съездлар һәм кушылмаларны минимумга кадәр киметүгә омтылырга кирәк.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Ә. Кадыйровка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Гатиятов